СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 28 » февраль 2022 ел** **№ 116**

**Арча муниципаль районының**
**вәкиллекле органы аппараты турында**

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе президиумының 2020 елның 9 декабрендәге ПР-187 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы муниципаль районы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре структурасын формалаштыру һәм штат санын билгеләү буенча методик рекомендацияләр нигезендә, Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген үстерү, идарә структурасын камилләштерү максатыннан Арча район Советы карар бирде:

1. Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты структурасына кадрлар секторын кертергә.

2. Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты структурасын, әлеге карарның 1 пунктына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Арча район Советы аппараты турында Нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4.Арча район Советының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Арча муниципаль районы вәкиллекле органы аппараты турында» Арча район Советының 2005 елның 28 декабрендәге 29 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты турында» Арча район Советының 2005 елның 28 декабрендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 31 гыйнварындагы 30 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты турында» Арча район Советының 2005 елның 28 декабрендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» (2011 елның 31 гыйнварындагы 30 номерлы үзгәрешләр белән) Арча район Советының 2015 елның 24 апрелендәге 334 номерлы карарын;

- «Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты турында» Арча район Советының 2005 елның 28 декабрендәге 29 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Арча район Советының 2018 елның 24 апрелендәге 170 номерлы карарын (31.01.2011 №30, 24.04.2015 №334 үзгәрешләр белән).

5. Әлеге карар 2022 елның 10 мартыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
28 февраль 22 ел, №116
карарына 1 нче кушымта

Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты
структурасы

«I. Аппарат бүлекләре.
1. Гомуми-оештыру бүлеге.
2. Юридик мәсьәләләр бүлеге.
3. Кадрлар секторы.

II. Аппаратның вазыйфаи затлары исемлеге.
1. Аппарат җитәкчесе.
2. Башлык ярдәмчесе.
3. Бүлек башлыгы.
4. Бүлек башлыгы.
5. Сектор мөдире.»

Арча район Советының
28 февраль 22 ел, №116
карарына 2 нче кушымта

**Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Арча муниципаль районының вәкиллекле органы (алга таба - вәкиллекле орган), Арча муниципаль районы башлыгы - вәкиллекле орган рәисенең йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру һәм вәкаләтләрне үтәү эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү максатыннан даими эшләүче орган - депутатлар булмаган хезмәткәрләр штатыннан торган вәкиллекле орган аппараты (алга таба - аппарат) төзелә.

2. Аппаратның бурычы - вәкиллекле орган, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, даими һәм вакытлы комиссияләр, депутат берләшмәләре һәм фракцияләр, башка органнар (алга таба - органнар), эшче, эксперт, киңәшмә төркемнәре эшчәнлеген хокукый, оештыру, кадрлар, матди - техник яктан тәэмин итү.

3. Аппарат үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Арча муниципаль районы Уставына, вәкиллекле орган регламенты һәм карарларына, әлеге Нигезләмәгә, Арча муниципаль районы башлыгының һәм аның урынбасарының хокукый актларына таяна.

4. Аппарат, вәкиллекле органның эш планнары нигезендә, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, аның бүлекләре белән үзара хезмәттәшлек итә.

5. Аппаратта, һөнәри берлекләрдән тыш, сәяси партияләр, дини һәм иҗтимагый берләшмәләр барлыкка килә алмый.

6. Аппарат вәкиллекле орган исеменнән юридик зат хокукларын гамәлгә ашыра, вәкиллекле органның герблы мөһерен кулланыла.

7. Аппарат штаты Арча муниципаль районы башлыгы раслаган штат расписаниесе нигезендә туплана. Аппарат хезмәткәрләре булып муниципаль хезмәткәрләр һәм техник персонал тора.

8. Аппарат эшчәнлеген муниципаль берәмлек башлыгы һәм аның урынбасары тикшереп тора.

9. Аппарат белән турыдан-туры вәкиллекле орган аппараты җитәкчесе идарә итә.

## II. Аппаратның төп бурычлары

10. Аппаратның төп бурычлары түбәндәгеләр:

- вәкиллекле орган, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, органнар һәм вәкиллекле орган депутатлары эшчәнлеген оештыру, мәгълүмати-аналитик, матди-техник һәм хуҗалык итү ягыннан тәэмин итү;
- вәкиллекле органның Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, башка дәүләт органнары белән элемтәләр оештыруны тәэмин итү;
- вәкиллекле органның Арча муниципаль районы Башкарма комитеты, җирле үзидарәнең башка органнары, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;
- вәкиллекле орган карарларының үтәлешен тикшереп тору эшендә катнашу;
- вәкиллекле органның иҗтимагый халыкара оешмалар, муниципальара хезмәттәшлек оешмалары, иҗтимагый хәрәкәтләр, сәяси партияләр, массакүләм мәгълүмат чаралары, хезмәт коллективлары, халык белән үзара хезмәттәшлеген оештыру;
- вәкиллекле орган депутатларына вәкаләтләрен (хокукларын һәм бурычларын) гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү.

## III. Аппаратның төп функцияләре

11. Куелган бурычларны үтәү өчен аппарат:

- вәкиллекле орган, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, органнар һәм вәкиллекле орган депутатларын оештыру, мәгълүмати, аналитик, хуҗалык, матди-техник яктан тәэмин итә;
- вәкиллекле орган, аның органнары утырышларын әзерләүне тәэмин итә;
- вәкаләтле органга керә торган документларны һәм мөрәҗәгатьләрне кабул итә, әлеге документлар һәм мөрәҗәгатьләр буенча кирәкле материалларны, шулай ук Арча муниципаль районы башлыгының һәм аның урынбасарының күрсәтмәләре проектларын әзерли;
- вәкиллекле орган, аның органнары утырышларында карала торган мәсьәләләр буенча кирәкле аналитик һәм белешмә материаллар әзерли, вәкиллекле органның эш планына кертү өчен тәкъдимнәр эшли, әлеге утырышларны оештыру ягыннан тәэмин итүне, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары катнашында үткәрелә торган киңәшмәләр һәм башка чаралар әзерләүне гамәлгә ашыра;
- Арча муниципаль районы башлыгының, аның урынбасарының вәкиллекле орган аппаратына кагылышлы күрсәтмәләрен гамәлгә ашыра;
- вәкиллекле орган депутатларының нәтиҗәле хокукый эшчәнлеге, әлеге процессны компьютерлаштыру өчен кирәкле мәгълүмат җыюны, эшкәртүне һәм саклауны оештыра, вәкиллекле органнар эше тәҗрибәсе буенча күзәтүләр әзерли;
- вәкиллекле органда эш алып баруны гамәлгә ашыра;

- вәкиллекле орган эше өчен кирәкле белешмәләр, исемлекләрне бастыруны оештыра, вәкиллекле органның мәгълүмати материалларын бастырып чыгаруны тәэмин итә;

- массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итә, матбугат чарасында бастырып чыгару өчен вәкиллекле орган материалларын әзерли;

- вәкиллекле орган, аның органнары утырышларында билгеләнгән депутат таләбен, тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алуны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- вәкиллекле орган карарлары һәм Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары күрсәтмәләре нигезендә башка функцияләр башкара.

## IV. Аппаратның структурасы

12. Аппарат түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

-гомуми- оештыру бүлеге;

- юридик мәсьәләләр бүлеге;

- кадрлар секторы.

13. Аерым бурычларны үтәү өчен аппарат составында башка структур бүлекчәләр дә төзелергә мөмкин.

14. Аппаратта түбәндәге вазыйфалар исемлеге билгеләнә:

- аппарат җитәкчесе;

- муниципаль берәмлек башлыгы ярдәмчесе;

-бүлек башлыгы;

- сектор мөдире;

- баш белгеч.

15. Аппарат вазыйфалары исеме штат расписаниесе белән билгеләнә.

16. Аппарат хезмәткәрләре Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары яисә аппарат җитәкчесе тәкъдиме белән Арча муниципаль районы башлыгы тарафыннан үз вазыйфасына билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә.

17. Аппарат хезмәткәрләренә Арча муниципаль районы башлыгы боерыгы нигезендә шәхес таныклыгы бирелә, аңа Арча муниципаль районы башлыгы имза куя.

## V. Аппаратның вазыйфаи затларының һәм бүлекчәләренең төп функцияләре

18. Аппарат җитәкчесе:

- аппаратның структур бүлекләре эшен оештыра һәм координацияли;

- аппарат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр, гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә аппарат исеменнән эш итә;

- вәкиллекле орган эшчәнлеген тәэмин итүгә бюджеттан бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә вәкиллекле орган чыгымнары сметасын төзи һәм башкара;

- вәкиллекле орган, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, вәкиллекле орган органнары һәм депутатлары эшчәнлеген финанс, матди - техник, хуҗалык ягыннан тәэмин итә;

- аппарат эшчәнлеген кадрлар белән тәэмин итә;

- вәкиллекле орган карарларын һәм басма чаралар әзерләү һәм бастырып чыгару эшен оештыра;

- вәкаләтле орган карарларының, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары күрсәтмәләренең, йөкләмәләренең, биремнәренең үтәлешен тикшереп тора;

- сайлау округларында вәкиллекле орган депутатларының эшен тәэмин итә;

19. Арча муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе:

1) муниципаль район чикләрендә коррупциягә каршы көрәш чараларын эшли һәм гамәлгә ашыра;

2) коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә сәясәтне эшләү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча доклад һәм (яисә) хезмәт язмалары, белешмәләр, башка материаллар һәм документлар әзерли;

3) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең башка органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан коррупциягә каршы законнарның үтәлешен тикшереп тора;

20. Арча муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе турыдан-туры Арча муниципаль районы башлыгына буйсына.

21.Гомуми- оештыру бүлеге:

- вәкиллекле органны, даими, вакытлы комиссияләрне, депутат берләшмәләре эшчәнлеген оештыру ягыннан тәэмин итә;

- вәкиллекле орган утырышларын алып бару тәртибен һәм аларның беркетмәләрен, вәкиллекле орган, аның органнары утырышларында әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр исемлеген рәсмиләштерә;

- Башкарма комитет белән үзара хезмәттәшлектә вәкиллекле орган каравына материаллар әзерләүне гамәлгә ашыра;

- вәкиллекле орган утырышлары, даими комиссияләр утырышлары турында депутатларга хәбәр итә, депутатларны теркәүне гамәлгә ашыра;

- депутатларга аларның эшләрен оештыруда методик ярдәм күрсәтә;

- депутатларга сайлау округлары территориясендә аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итә;

- депутат таләпләрен исәпкә алуны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

- вәкиллекле орган, даими комиссияләр эшенең перспектив һәм агымдагы планнары проектларын эшләүне һәм аларның үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итә;

- вәкиллекле орган карарларының үтәлешенә анализ ясый;

- тиешле мәгълүматны даими комиссияләргә, вәкиллекле орган органнарына һәм депутатларына, Арча муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыра;

- Арча муниципаль районы башлыгы кушуы буенча бүлек компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча оешмалар сорауларына һәм гражданнар мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерли;

- үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү барышында Арча муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекләре белән хезмәттәшлек итә;

- Арча муниципаль районы бүләкләрен бирү турында документлар әзерләүне тәэмин итә;

- корреспонденцияне кабул итә, исәпкә ала һәм җибәрә, вәкиллекле орган һәм аппарат эшчәнлеген документаль тәэмин итә;

- вәкиллекле орган утырышларында беркетмә алып баруны тәэмин итә;

- вәкиллекле орган һәм аппарат эшен мәгълүмати-технологик, мәгълүмат системасын төзү һәм озата бару ягыннан тәэмин итә;

- вәкиллекле орган карарларын исәпкә ала һәм системага сала;

- вәкиллекле органның эшен алып бара һәм архивын формалаштыра;

- норматив-хокукый актлар реестрын алып бара.

22. Юридик мәсьәләләр бүлеге:

- вәкиллекле органның, Арча муниципаль районы башлыгының, аның урынбасарының, даими комиссияләрнең нормалар билгеләү һәм агымдагы эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итә;

- вәкиллекле орган, аның органнары утырышлары эшендә катнаша;

- вәкаләтле орган, даими комиссияләр карарлары проектларына, Арча муниципаль районы башлыгының, аның урынбасарының хокукый актларына, вәкаләтле органның шартнамәләренә, башка документларына хокукый экспертиза уздыра;

- Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары кушуы буенча вәкиллекле органның карарлары проектлары, вәкиллекле орган эшчәнлегенә бәйле башка мәсьәләләр буенча белешмәләр һәм бәяләмәләр әзерли;

- гомуми юрисдикция судларында, арбитраж судларда, юстиция һәм прокуратура органнарында вәкиллекле орган исеменнән эш итә;

- гражданнарның, оешмаларның хатларына, прокуратура органнары, хокук саклау, контроль һәм башка күзәтчелек органнары күрсәтмәләренә һәм протестларына җаваплар әзерләүдә,катнаша.

23. Кадрлар секторы:

- муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар составын формалаштыра;

- муниципаль хезмәт турында законнар нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр әзерли һәм Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары каравына кертә;

- муниципаль хезмәткә керүгә, аны узуга, хезмәт шартнамәсе (контракты) төзүгә, муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куюга, муниципаль хезмәткәрне биләгән муниципаль хезмәттән азат итүгә, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән китүенә һәм пенсиягә чыгуына бәйле муниципаль хокукый актлар проектларын әзерләүне һәм тиешле документларны рәсмиләштерүне оештыра;

- Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль

хезмәткәрләренең реестрын, Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын алып бара;

- кадрлар резервы белән эшләүне һәм аннан нәтиҗәле файдалануны оештыра;

- Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасына кадрлар составы турында мәгълүмат кертә;

- муниципаль хезмәткәрләргә ташламалар һәм гарантияләр бирү өчен муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгара;

- аттестация комиссиясе, муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итә;

- Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең квалификация имтиханын әзерләү һәм үткәрүне тәэмин итә;

- муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрүне тәэмин итә;

- Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда, башка федераль законнарда, шулай ук Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итә (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр);

- муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрә;

- Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфа биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итүдә катнаша;

- үз компетенциясе чикләрендә нинди дә булса затларның коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, башка дәүләт органнарына мөрәҗәгатьләренең барлык очраклары турында муниципаль хезмәткәрләрнең хәбәр итү бурычларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә катнаша;

- хезмәт тикшерүләре үткәрә;

- муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә тапшырыла торган белешмәләрнең (коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлешендә) дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәүләрен тикшерә;

- коррупциягә каршы көрәш турында норматив хокукый актлар проектларын әзерли;

- муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү турында, алар өчен билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм йөкләмәләрне үтәмәүне булдырмау яисә җайга салу турында, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнар тарафыннан муниципаль хезмәттән киткәннән соң хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) граждан-хокук шартнамәсе төзегәндә федераль законнарда билгеләнгән тыюларны үтәү турында белешмәләрне анализлый, шулай ук мондый белешмәләрне анализлаганда әлеге гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр белән алар ризалыгы белән әңгәмә үткәрә, алар ризалыгы белән алардан аңлатмалар ала, Россия Федерациясе Прокуратурасы органнарыннан, башка федераль дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү турында мәгълүмат ала (дәүләт, банк, салым яки закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итүче мәгълүматлардан тыш), гражданнар яки муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән мәгълүматларны, алынган башка мәгълүматны өйрәнә.

24. Аппарат бүлекләренең башка функцияләре Арча муниципаль районы башлыгы раслаган аппарат бүлекләре турындагы нигезләмәләр нигезендә билгеләнә.

25. Аппарат хезмәткәрләренең хокуклары һәм бурычлары хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар, аппарат бүлекләре турындагы нигезләмәләр һәм (яисә) вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

26. Аппарат хезмәткәрләре Арча муниципаль районы башлыгына, аның урынбасарына, вәкиллекле орган аппараты җитәкчесенә, тиешле бүлек башлыгына, сектор мөдиренә буйсыналар.

## VI. Йомгаклау нигезләмәләре

27. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр аппарат бүлекләре нигезләмәләре, вазыйфаи инструкцияләр, хезмәт контрактлары, Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары, аппарат җитәкчесенең башка локаль хокукый актлары нигезендә җайга салынырга тиеш.

28. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр вәкиллекле орган тарафыннан Арча муниципаль районы башлыгы, аның урынбасары тәкъдиме буенча кертелә.